# Презентация

Галиуллина Гөлсинә Әнвәр кызы
Карга төп гомуми белем бирү мәктәбе

# Фонетика

## Сузык авазлар

# Сузык авазларның үзенчәлеге

- Сузык авазларны әйткәндә без тавыш ишетәбез.
- Сузык авазларны әйткән вакытта үпкәдән килгән һава агымы бернинди каршылыкка да очрамый.

# Татар телендә сузык авазлар

- Татар телендә барлыгы 12 сузык аваз кулланыла.
- Шуларның 9-ы татар теленең үз сузыклары : [а][ә][о][ө][у][ү][ы][и][э]
- 3 сузык аваз рус теленнән кергән, алар - [о][ы][э]

# Сузыкларны төркемләү

- Әйтү үзенчәлеге буенча сузык авазларны калын һәм нечкә сузыкларга бүләләр.
- Калын сузыкларны икенче төрле арткы рәт сузыклар дип атыйлар.
- Нечкә сузыкларны исә алгы рәт сузыклар дип атыйлар.
- Арткы рәт сузыклар: [а][о][у][ы][о][ы]
- Алгы рәт сузыклар: [ә][ө][ү][и][э][э]

# Сузыкларны төркемләү

- Иренләшкән сузык авазлар:

  [о] [ө] [у] [ү] [о]

- Иренләшмәгән сузыклар:

  [а] [ә] [ы] [и] [э] [ы] [э]

# Сузыкларны төркемләү

- Парлы сузыклар:
  - [а] - [ә]
  - [о] - [ө]
  - [у] - [ү]
  - [ы] - [э]

# Дифтонг

- Бер иҗектә 2 сузык авазның янәшә килүе **дифтонг** дип атала.
- Татар теленең дифтонглары - ау/әү, яу/яү. Мәсәлән: *бау*, *дәү*, *буяу*, *кияү*.
- Сүзләрне төрләндергәндә, дифтонгларның составы үзгәрә: алар ике иҗеккә бүленәләр, язуда ***у***, ***ү*** хәрефләре урынына ***в*** хәрефе кулланыла: олау - олавы, яу - явы.

# Сингармонизм законы. I төре

- Сузыкларның нечкәлектә-калынлыкта ярашуы **сингармонизм законының I төре** дип атала.
- Мәсәлән: *урманчы* сүзендә [у],[а],[ы] кебек калын сузыклар гармониясе күзәтелә, ә *бөркәнчек* сүзендә исә [ө][ә][э] нечкә сузыкларын ишетәбез.
- Законның әлеге төре икенче төрле **рәт гармониясе** дип атала.

# Искәрмә!

- Кайбер сүзләрдә (мәсәлән, алынмаларда, кушма сүзләрдә) сингармонизм законының бу төре – рәт гармониясе үтәлмәскә дә мөмкин.

Китап - [и] – алгы рәт сузыгы

[а] – арткы рәт сузыгы

Айгөл - [а] – арткы рәт сузыгы

[ө] – алгы рәт сузыгы

Бу очракта сүз сингармонизм законына буйсынмый дияләр.

# Сингармонизм законы. II төре

- Сүзнең беренче иҗегендә о,ө хәрефе булып, икенчә иҗектә ы,э хәрефләре килсә, беренче иҗектәге [о],[ө] авазлары тәэсирендә икенче иҗектә дә шул ук [о],[ө] авазларын ишетәбез, әйтәбез.
- Мәсәлән: бөре – [б][ө][р][ө], тозлы – [т][о][з][л][о].
- Законның бу төре икенче төрле **ирен гармониясе** дип тала.

# Сузыкларның кыскаруы

Кайбер сүзләрдә басымсыз иҗекләрдә килгән [ы][э] сузык авазлары мускул киеренкелеге киму нәтиҗәсендә йотылалар яки әйтелмиләр.

Әлеге күренеш сузыкларның кыскаруы, фәнни телдә **редукция** дип атала.

Мәсәлән: сеңелем – [сэңлэм]

авыру - [ awpy ]

# Алынмалардагы сузыкларның үзгәреше

- Рус теле аша кергән сүзләрдә басымлы иҗек алдыннан килгән [<u>о</u>] авазы [а] авазы булып әйтелә. Мәсәлән: п<u>о</u>ртрет, к<u>о</u>рсет.
- Рус теле аша кергән сүзләрдә басымлы иҗектән соң килгән [<u>о</u>] авазы [ы]авазы булып әйтелә. Мәсәлән: архитект<u>о</u>р, директ<u>о</u>р.

# Кабатлау өчен сораулар

- Нәрсә ул фонетика?
- Сузык авазларга нинди үзенчәлек хас?
- Татар телендә барысы ничә сузык бар?
- Сузык авазларны ничек төркемлибез?
- Нәрсә ул дифтонг?
- Сингармонизмның I төре нидән гыйбарәт?
- Сингармонизм законына нинди сүзләр буйсынмый?
- Ирен гармониясенең мәгънәсе?
- Нәрсә ул редукция?мисаллар ярдәмендә аңлатыгыз.
- Алынмаларда нинди үзгәрешләр күзәтелә?

# Йомгаклау

Сез “Фонетика” курсының “Сузык авазлар” бүлеген уңышлы үттегез. Тәбрик итәбез. Инде “Тартык авазлар” бүлегенә рәхим итегез!

**Афәрин!**